**Республика Татарстан**
**Глава Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11. 2020г № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегең Югары Чыршылы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итэм:

1. Югары Чыршылы авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 13 ноябренә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан , Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмэткэ чакырылган затлардан, кондезге формада белем алучы студентлардан тыш 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча жирле әһэмияткэ ия мэсьэлэлэрне хэл итугэ алынган акчаларны жибэругэ килешэсезме?:

- Югары Чыршылы авылында балалар өчен уен җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру;

- Югары Чыршылы авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу;

- оешма территорияләрен һәм юл буйларын чабу буенча эшләр өчен түләү ;

- Югары Чыршылы мәдәният йорты территориясендә төзелеш материаллары сатып алу һәм койма урнаштыру буенча эш өчен түләү;

- МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

«ӘЙЕ «ЮК»

3.Югары Чыршылы авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.
4.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдинов